БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

11 сентябрь 2025 ел № 341

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль милкенә караган, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләре) бердәм дәүләт реестрына кертелгән, торышы канәгатьләнерлек булмаган файдаланылмый торган мәдәни мирас объектлары өчен ташламалы аренда түләвен билгеләү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2025 елның 16 маендагы «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 667 номерлы карарына туры китереп, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район Советы карар кылды:

1. Балтач район Советының 2019 елның 15 мартындагы 167 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль милкенә караган, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләре) бердәм дәүләт реестрына кертелгән, торышы канәгатьләнерлек булмаган, файдаланылмый торган мәдәни мирас объектлары өчен ташламалы аренда түләвен билгеләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 8 пунктның а пунктчасын «, шулай ук әлеге мәдәни мирас объектының дини билгеләнештәге мөлкәт булып саналмавы яисә «Дәүләт милкендә яки муниципаль милектә булган дини билгеләнештәге мөлкәтне дини оешмаларга тапшыру турында» Федераль законның 5 статьясындагы 3 өлешендә һәм (яисә) 12 статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән мөлкәт булып саналмавы хакындагы белешмәләрне» сүзләре белән тулыландырырга;

1.2. 2 пунктта «Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән» сүзләрен «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләре) турында» Федераль законда билгеләнгән» сүзләренә алмаштырырга;

1.3. Кушымтаның 6 пунктындагы 2 абзацында «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 елның 29 июнендәге «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләре) бердәм дәүләт реестрына кертелгән мәдәни мирас объектларын торышы канәгатьләнерлек

булмаган мәдәни мирас объектларына кертү критерийларын раслау турында» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (http://baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына йөкләргә.

Балтач муниципаль район башлыгы,
Балтач район Советы рәисе Р.Р.Нотфуллин